ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2024 г.Казань № 376-21/тэ-2024

Кулланучыларга «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 ел, №221-28/тэ-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларны 2025 ел өчен төгәлләштерү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 12.12.2024 ел, №31/1-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2025 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2025 елга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында» 11.11.2020 ел, №221-28/тэ-2020 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.11.2022 ел, №451-40/тэ-2022, 08.12.2023 ел, №432-20/тэ-2023 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән билгеләнгән

тарифларны 2025 ел өчен төгәлләштереп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 ел, №221-28/тэ-2020 карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2024 № 376-21/тэ-2024 карары редакциясендә)

## 2021-2025 елларга «Теплокоминвест» ЖЧЖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Теплокоминвест» ЖЧЖ <*> | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1 682,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1 723,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1 723,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1 792,71 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1 744,63 <**> | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1 744,63 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1 932,63 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап | 1 932,63 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 30.06.2025 кадәр | | | | | | |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 162,79 | - | - | - | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана, Россия Федерациясе Салым кодексының 145 статьясы нигезендә өстәлгән бәягә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүче вазыйфаларын башкарудан азат ителгән.

<**> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге